| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 23 » 12 2020 № 790

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звенолары турында» 2016 ел, 12 июль, 364 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органнарын үзгәртеп кору һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 ел, 1 июль, 534 нче карары, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органнарын оештыру-штат чаралары белән бәйле рәвештә үзгәртеп кору чаралары турында» 2011 ел, 1 август, 280 нче боерыгы һәм оештыру-штат чаралары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 декабреннән Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең Аксубай муниципаль районы буенча әйдәп баручы консультанты Савельева Людмила Николаевнаны Аксубай муниципаль районы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе секретаре вазыйфаларыннан азат итәргә һәм комиссия әгъзалары составында калдырырга.

2. Аксубай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына (5 нче кушымта) «Аксубай муниципаль районы гражданнар саклау идарәсе» МКУ җитәкчесе Шаязданов Фирнат Фәхертдин улын кертергә һәм аңа Аксубай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе секретаре вазыйфаларын йөкләргә.

3. Аксубай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе документларын Ф.ф. Шаяздановка акт буенча тапшырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга: http:/ / pravo. tatarstan. ru.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Зайцев